**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail:Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

____________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　_______

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 августындагы ПР-563 номерлы «Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Югары сыйфатлы алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату күләмен арттыру, аның ассортиментын киңәйтү, шулай ук эчке куллану базарыннан ялган продукцияне кысрыклап чыгару, шулай ук кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 августында кабул ителгән ПР-563 номерлы карарының 1 пунктына үзгәреш кертергә һәм 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2013 елның 19 августындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 01 мартындагы ПР-34 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru.үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
___________ 2023 ел, №___ карарына
кушымта

**Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; | Комиссия рәисе |
| Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; | Комиссия рәисе урынбасары |
| Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы, координация Советы секретаре. | Комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары*: | |
| -Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы бүлеге башлыгы; | |
| -Актаныш районы суд приставлары хезмәте бүлеге башлыгы, өлкән суд приставы; | |
| «Актаныш район үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы; | |
| -ТР буенча РФ ФНС МРИ баш дәүләт салым инспекторы; | |
| ТР буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге территориаль идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы урынбасары; | |
| -ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы башлыгы; | |
| «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; | |
| «Актаныш мәгълүмат-редакция үзәге» ААҖ филиалы директоры; | |
| - Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; | |
| - Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы; | |

* - Башкарма комитет җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган барлык затлар килешү буенча эшче төркеме составына кертелә.